ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 28 » ноября 2024 ел** **№ 18**

**Адрес бирү объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында" 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, «Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе турында»2022 елның 2 мартындагы 145 номерлы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Адрес бирү объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетының

түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- "Адрес бирү объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 16.03.2022 № 8;

"Адрес бирү объектына адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 07.10.2024 №13”.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. Х. Хәбибуллин